ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘҖМӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КАРАР

N14 12.03.2025 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Әҗмәр авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Әҗмәр авыл җирлеге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибен раслау турында» 2022 елның 03 ноябрендәге 32 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Әҗмәр авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Җир кодексына, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 5 статьясындагы 2 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» 2024 N 485-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Әҗмәр буе авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Әҗмәр авыл җирлеге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибенә «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Әҗмәр авыл җирлеге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Әҗмәр авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 03 ноябрендәге 32 номерлы карары белән расланган түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1 пунктта "керемнәрдән тыш" сүзләреннән соң "дүртенче һәм бишенче категорияле автомобиль юллары һәм" сүзләрен өстәргә.;

1.2. 3.8 пунктта «килешүен» сүзен «килештерүне» сүзенә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Спас муниципаль районының
Әҗмәр авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе

Р.М.Вәлитов